ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КЫЗЫЛТАУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

КАРАРЫ

2023 ел, 3 июль №93

Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Кызылтау авыл җирлегенең муниципаль хезмәткәрләренең коррупция хокук бозулары өчен җаваплылыгы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

2023 елның 13 июнендәге N258-ФЗ номерлы "Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" Федераль законы нигезендә, Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Кызылтау авыл җирлеге Советы карар итте:

1. 2012 елның 14 ноябрендәге 23 номерлы Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Кызылтау авыл җирлеге Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Кызылтау авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең коррупция хокук бозулары өчен җаваплыллыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәреш кертергә:

2.5 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“коррупцияне һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча тиешле муниципаль органның кадрлар хезмәте бүлекчәсе яки “Коррупциягә каршы тору турында" 2008 елның 25 декабрендәге N 273-ФЗ Федераль законның 13.4 статьясына ярашлы рәвештә Россия Федерациясе Президенты Администрациясенең вәкаләтле бүлеге тарафыннан үткәрелгән тикшерү нәтиҗәләре нигезендә;”.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырырга.

3.Бу карарның үтәлешен контрольләүне җирлек башлыгына йөкләргә.

Кызылтау авыл җирлеге башлыгы-
Кызылтау авыл җирлеге Советы Рәисе М.Г.Нуриев